# Иҗади сәхифә

№ 2

февраль, 2020

Сәхифәне оештыручылар: 3 нче мәктәпнең 6нчы В сыйныфы укучылары

**Ай-кояштай сүнми, балкып яшә,**
**Туган җирем - Татарстаным!**

**Урнашуы**: Россия Федерациясе үзәгендә, Көнчыгыш Европа тигезлегендә, Идел һәм Кама елгалары кушылган җирдә.

**Мәйданы**: 67836,2 кв.км.

**Башкаласы**: Казан шәһәре (Мәскәүдән 797 км., 1 млн. 144 мең кеше).

**Административ-территориаль бүленеше**: 43 муниципаль район һәм 2 шәһәр округы (Казан һәм Чаллы).

**Хөкүмәте**: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты. Татарстан Республикасы Премьер-министры – Песошин Алексей Валерьевич.

**Парламенты**: бер палаталы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе – Мөхәммәтшин Фәрид Хәйрулла улы.

**Халкы**: саны – 3 898 630 кеше (2019 ел), татарлар – 53,2%, руслар – 39,7%.














Татарстан Республикасы Дәүләт гимны
(Рамазан Байтимеров сүзләре, рус теленә Филипп Пираев тәрҗемәсе)

Мәңге яшә, газиз Ватаныбыз,
Халкым тели изге теләкләр!
Гомерлеккә якын туган булып
Яши бездә төрле милләтләр.
Күп гасырлар кичкән чал тарихлы
Данлы илем, үзең бер дастан!
Синдә генә безнең язмышыбыз,
Республикам минем, Татарстан!

Цвети, священная земля моя,
Да будет мирным твой небосвод!
Единый дом у нас, одна семья,
Живет в согласии наш народ.
Богатый мудростью седых веков,
Надеждой, верою ты нам стал,
И пусть хранит тебя моя любовь,
Моя Республика, мой Татарстан!

**Нинди матур, нинди гүзәл безнең**
**Казан дигән данлы башкала.**
**Кайсы илдән кем генә килсә дә,**
**Бу каланы күреп таң кала.**
**Р.Нургалиева**



Акрамов Камаль, 3нче Г сыйныфы

# Минзәләм

Минзәлә - туган шәһәрем,
Якын һәрбер урамы.
Язлар житкәч яшелләнә
Урманнары, кырлары.
Бәйрәмнәре гөрләп тора
Ел буена шәһәрдә.
Безгә кунакка килегез
Сез өченче мәктәпкә.

Вәлиева Азалия, 2нче Г сыйныфы



Фатхуллин Алмаз, 4нче Б сыйныфы



Иванова Аделия, 2нче В сыйныфы

# Татарстаным

Татарстан - минем туган жирем,
Күңелгә якын кешеләре.
Татарстан - минем туган ягым,
Иркен кырлары, урманы.
Татарстан - минем киләчәгем,
Тормышта үтәсе юлларым.

Акимова Эльвина, 4нче В сыйныфы



Шабаев Ирек, 4нче Б сыйныфы

# Минзәлә - туган ягым

Туган як, туган жир, газиз Ватан... Минем туган-үскән жирем - Минзәлә шәһәре. Минем өчен иң матур, иң гүзәл як. Ул истәлекләргә, тарихи вакыйгаларга бай. Безнең генә түгел, борынгы бабаларыбызның да торган жире, гомер бишеге.

Хабибуллина Алия, 4нче В сыйныфы

Илһам чишмәсе

Яшәсен, үссен мул Татарстан!

Туган илебезгә, туган илгә дан!

Бу җырны җырлый татарлар, руслар.

Без барыбыз да мәңгелек дуслар.

Ж.Тәрҗеманов.



Шамсуллина Диана, 3нче Гсыйныфы




Лисунова София, 2нче В сыйныфы





Чугунова Алина, 4нче Б сыйныфы

# Татарстан - бердәм республика.

Мин Татарстан республикасында яшәвем белән горурланам. Бездә төрле милләт кешеләре дус яшиләр. Алар бер-берсен хөрмәт итәләр. Милли бәйрәмнәрдә төрле халыклар бик теләп катнашалар. Ямьле җәй көннәренең берсендә уздырыла торган Сабантуй бәйрәмендә нинди генә милләт кешеләре катнашмый? Бәйрәмдә рәхәтләнеп ял итәбез, күңел ачабыз.

Хакимов Руслан, 6нчы В сыйныфы




Юнзель Егор, 4нче Б сыйныфы




Федорова Илүзә, 4нче Б сыйныфы

## Зирәкләр аланы


## Дәвам ит

1. Ил иле белән, бака ...
2. Илсез кеше - телсез ...
3. Туган илнең кадерен ...
4. Халык йорты - ...
5. Һәр гөл үз сабагында ...





1. Республикабызның башкаласы.
2. Гербта нәрсә сурәтләнгән?
3. Президентның исеме.
4. Флагтагы төс.
5. Республикабызның символикасы.
6. Без яшәгән республика.

Шайхразиев Тимур, 6нчы В сыйныфы




Ка

## Сүзләрне эзләп тап




Новикова Мария, 6нчы В сыйныфы



Фардиева Эллина, 6нчы В сыйныфы

## Мисалларны чиш




Ильина Элина, 6нчы В сыйныфы